КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 24 декабрь г.Казань № 1133

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче; 2020 ел, 6 июль, 555 нче; 2021 ел, 21 апрель, 268 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1316 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1493 нче; 2023 ел, 1 март, 195 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 13 июль, 823 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 23 август, 1003 нче; 2023 ел, 31 август, 1054 нче; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче; 2023 ел, 10 октябрь, 1293 нче; 2023 ел,

11 декабрь, 1599 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 13 февраль, 76 нчы; 2024 ел, 25 май, 365 нче; 2024 ел, 8 июль, 537 нче; 2024 ел, 2 август, 614 нче; 2024 ел, 4 декабрь, 1093 нче; 2025 ел, 1 февраль, 56 нчы; 2025 ел, 17 март, 153 нче; 2025 ел, 18 октябрь, 839 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.3 пунктның өченче – алтынчы абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

3.4.1[1] пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1[1]. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм бүлегендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм хезмәтләре (алга таба – иртә ярдәм күрсәтү) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтү стандартын раслау турында» 2025 елның 30 маендагы 344н номерлы боерыгы белән расланган Балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтү стандарты (алга таба – иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтү стандарты), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «-Татарстан Республикасында балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм күрсәтүне оеш-тыру һәм гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне һәм Татарстан Респубикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2025 ел, 26 июнь, 461 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында балаларга һәм аларның гаиләләренә иртә ярдәм күрсәтүне оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы нигезләмә нигезендә күрсәтелә.

Иртә ярдәм хезмәтләре составына керә торган чаралар исемлеге иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтү стандартының V бүлегендә китерелде.

Иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтү составына керә торган чараларның эчтәлеге иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтү стандартының VI бүлегендә күрсәтелде.

Иртә ярдәм хезмәтләре составына керә торган чаралар иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтү стандартының VII бүлегендә билгеләнгән дәвамлылык һәм кабатлану ешлыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтү чорында җиһазландырылган бүлмәләр бирелә, аларның мәйданы бер иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтелүче өчен кимендә 18 кв.метр тәшкил итәргә тиеш. Иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтелүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган нормативлар нигезендә йомшак инвентарь (кечкенә келәм, сөлге һ.б.) һәм санитария-гигиена билгеләнешендәге товарлар (бәдрәф кәгазе, сабын) белән тәэмин ителә.»;

3.4.2 пунктта:

бишенче абзацта татар текстында «сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен» сүзләреннән соң «(мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлегендәге иртә ярдәм һәм социаль хезмәтләр күрсәтү бүлегендә иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтүдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта татар текстында «иртә ярдәм һәм көндезге бүлекләрендә социаль хезмәтләр» сүзләрен «көндезге бүлегендәге иртә ярдәм һәм социаль хезмәтләр бүлегендә иртә ярдәм хезмәтләре» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта татар текстында «иртә ярдәм һәм көндезге бүлекләрендә социаль хезмәтләр» сүзләрен «көндезге бүлегендәге иртә ярдәм һәм социаль хезмәтләр бүлегендә иртә ярдәм хезмәтләре» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.2[1] пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.4.5 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.4.7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Тәртипнең 2[1] нче кушымтасы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин